**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
Глава
Какре-Елгинского
сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

423320 с.Какре-Елга
ул.Советская, 22,
Тел. 37-0-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Кәкре-Елга авыл җирлеге
башлыгы

Кэкре-Елга авылы, 423320
Совет урамы, 22,
Тел. 37-0-49

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от «19» октябрь 2020 г. № 3

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Якты Юл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Якты Юл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 28 нче октябренэ билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2020 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Якты Юл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 200 сум куләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Якты Юл бистәсендә су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү) ;

- Якты Юл бистәсендә юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);

- Якты Юл бистәсе территориясен җәйге вакытта чабу (килешү буенча эшләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык И.М.Мухаметзянов

КАКРЕ-ЕЛГИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ